| | | |
|---|---|---|
| **«Хуплыйм»** | **«Раслыйм»** | **«Раслыйм»** |
| **«Сәләт» проектлары житәкчесе** | **«Сәләт» ТТЯФ Генераль директоры** | **«Сәләт» яшьләр үзәге директоры** |
| **________Әдип Әлмир** | **______Э.Р. Насибуллина** | **______А.Т. Габдрахманова** |
| **«08» октябрь 2024 ел** | **«08» октябрь 2024 ел** | **«08» октябрь 2024 ел** |

**XXIII Республикакүләм Рөстәм Бикмуллин исемендәге яшьләр җыр-шигырь «БикаФест» фестивален үткәрү**

**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## 1. Фестивальне оештыручылар

Республикакүләм Рөстәм Бикмуллин исемендәге яшьләр җыр-шигырь «БикаФест» фестивале (алга таба – «БикаФест») Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы ярдәме белән «Сәләт» Клубы, «Сәләт» яшьләр үзәге Дәүләт учреждениесе һәм «Сәләт» Татарстан төбәк яшьләр фонды тарафыннан оештырыла.

## 2. Фестивальнең максатлары

Фестиваль үз алдына түбәндәге бурычларны куя һәм тормышка ашыра:

- иҗатка сәләтле балаларны яшьтән барлау, сәләтләрен, мөмкинлекләрен ачу өчен кирәкле шартлар булдыру, алар белән максатлы рәвештә һәм даими эшләү, аларның проблемаларына дәүләт органнары һәм җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү;
- җыр һәм шигърият өлкәсендә сәләтле балалар һәм яшьләрне барлау, аларга ярдәм итү;
- балаларда һәм яшьләрдә эстетик зәвык, музыкаль һәм шигъри культура тәрбияләү;

- сәләтле балалар һәм яшьләр – республиканың интеллектуаль-рухи потенциалы булуын тагын да ассызыклау, җәмәгатьчелеккә җиткерү;
- сәләтле балаларның һәм яшьләрнең дусты, фикердәше, яшьләр лидеры, меценат автор-башкаручы Рөстәм Бикмуллинның истәлеген мәңгеләштерү.

## 3. Фестивальнең үткәрелү вакыты һәм урыны

3.1. «БикаФест» ике этапта үткәрелә:

1-нче этап – гаризаларны кабул итү һәм катнашучыларны читтән торып портфолиолар нигезендә сайлап алу (соңгы 2 ел казанышлары кабул ителә).

2-нче этап – катнашучыларны конкурс нигезендә сайлап алу.

3.2. 8-нче октябрь – 8-нче ноябрь – гаризаларны кабул итү, катнашучыларны сайлап алу этабы.

3.3. Беренче этап нәтиҗәсендә катнашучылар икенче этапка – конкурска чакырыла. Ул 2024-нче елның 22-нче ноябрь көнне «Йолдызлы» БСА (Лаеш районы, Троицкий бистәсе) узачак.

3.4. Конкурс нәтиҗәсендә фестивальнең Гала-концерты булачак. Ул 2024-нче елның 23-нче ноябрь көнне Лаеш районы, Троицкий бистәсе «Йолдызлы» БСА адресы буенча узачак. Гала-концертта «БикаФест» җиңүчеләре тантаналы рәвештә бүләкләнәчәк.

## 4. Фестивальнең казыйлар шурасы

4.1. Фестивальнең казыйлар шурасы Татарстан Республикасының танылган һәм мактаулы мәдәният эшлеклеләренниң оста автор-башкаручыән тора.

4.2. Казыйлар шурасы конкурсантлар арасыннан «БикаФест» фестиваленең җиңүчеләрен билгели.

4.3. Казыйлар шурасының карарын казыйлар шурасы рәисе раслый, һәм ул протокол белән беркетелә.

4.4. Протокол нигезендә эшләнгән казыйларның фикере ахыргы фикер булып санала.

## 5. Фестивальдә катнашучылар

5.1. «БикаФест» фестивалендә иҗади коллективлар һәм аерым чыгыш ясаучылар катнаша. Катнашучыларның яше 12-дән алып 25-кә кадәр. Алар төрле вокал юнәлешендә һәм нәфис сүз осталыгында ярыша ала.

5.2. «БикаФест» фестиваленең катнашучылары әлеге нигезләмәнең шартларын үтәргә тиеш.

5.3. Конкурста катнашырга теләк белдерүчеләргә гариза җибәрергә һәм портфолионы оештыручыларга тәкъдим итәргә кирәк. Гаризалар Сәләт оешмасының рәсми сайтында (selet.biz) 8-нче ноябрь, сәгать 23:59 кадәр кабул ителә.

5.4. Фестивальдә катнашучы коллективларда башка яшьтәге катнашучылар саны коллектив әгъзаларының 25%-ыннан артык булмаска тиеш. Ике кешедән торган иҗат коллективлары да 50% /50% нисбәте рөхсәт ителә.

5.5. Гаризалар сылтама: https://forms.gle/3A15sm4JbLMCVfWcA буенча кабул ителә. Игътибар итүегезне сорыйбыз: гаризада музыкаль юнәлештә катнашучыга чыгышының видео-файлын, ә әдәби юнәлештә катнашучыга чыгыш тексты язылган файлны беркетергә кирәк.

5.6. Фестивальнең казыйлар шурасы конкурс нигезендә Гала-концертның катнашучыларын билгели.

5.7. Конкурста катнашучыларның чыгыш ясау тәртибен фестивальнең оештыручылары билгели.

## 6. Фестивальнең катнашучыларына куелган шартлар

6.1. «БикаФест» фестивале ике юнәлештә үткәрелә:

1. Музыкаль юнәлеш:

1.1 <u>иң оста автор башкаручы </u> (бу номинациядә җырның көен һәм сүзләрен үзләре иҗат иткән вокалистлар катнаша ала, җырны фонограммага да (минус), шулай ук тере аккомпанементка да башкарырга мөмкин)

- 12-дән 15-кә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр;

- 21-дән 25-кә кадәр;

1.2 автор җырын иң оста башкаручы коллектив (бу номинациядә җырның көен һәм сүзләрен үзләре иҗат иткән коллективлар катнаша ала, җырны фонограммага да (минус), шулай ук тере аккомпанементка да башкарырга мөмкин)

- кече форма (дуэт, трио);
  - 12-дән 15-кә кадәр;
  - 16-дан 20-гә кадәр;
  - 21-дән 25-кә кадәр;
- ансамбль (дүрт катнашучыдан алып);
  - 12-дән 15-кә кадәр;
  - 16-дан 20-гә кадәр;
  - 21-дән 25-кә кадәр;

1.3. иң оста коллектив-башкаручы (бу номинациядә катнашучы коллективлар җырны фонограммага (минус)/тере аккомпанементка/а капелла башкара ала)

- кече форма (дуэт, трио);
  - 12-дән 15-кә кадәр;
  - 16-дан 20-гә кадәр;
  - 21-дән 25-кә кадәр;
- ансамбль (дүрт катнашучыдан алып);
  - 12-дән 15-кә кадәр;
  - 16-дан 20-гә кадәр;
  - 21-дән 25-кә кадәр;

1.4 татар халык җырын иң оста башкаручы (бу номинациядә катнашучы вокалистлар татар халык җырын фонограммага (минус)/тере аккомпанементка/а капелла башкара ала)

- 12-дән 15-кә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр (һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары укучылары һәм аларны тәмамлаучылар);
- 21-дән 25-кә кадәр;

- 21-дән 25-кә кадәр (һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары укучылары һәм аларны тәмамлаучылар);

1.5 <u>татар композиторларының академик әсәрен иң оста башкаручы </u>(бу номинациядә катнашучы вокалистлар татар композиторлары язган романслар/арияләрне тере аккомпанементка/фонограммага (минус) башкара ала)

- 12-дән 15-кә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр (һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары укучылары һәм аларны тәмамлаучылар);
- 21-дән 25-кә кадәр;
- 21-дән 25-кә кадәр (һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары укучылары һәм аларны тәмамлаучылар);

1.6 <u>эстрада җырын иң оста башкаручы</u> (бу номинациядә катнашучы вокалистлар эстрада җырларын фонограммага (минус)/тере аккомпанементка башкара ала)

- 12-дән 15-кә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр (һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары укучылары һәм аларны тәмамлаучылар);
- 21-дән 25-кә кадәр;
- 21-дән 25-кә кадәр (һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары укучылары һәм аларны тәмамлаучылар).

2. Әдәби юнәлеш:

2.1 <u>үз әсәрен иң оста укучы</u> (бу номинациядә шигърият/проза/әдәби-музыкаль композиция жанрларында үзләре иҗат иткән әсәрне яттан укучылар катнаша ала)

- 12-дән 15-кә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр;
- 21-дән 25-кә кадәр;

2.2 <u>башка автор әсәрен иң оста укучы</u> (бу номинациядә шигърият/проза/әдәби-музыкаль композиция жанрларында әсәрне яттан укучылар катнаша ала)

- 12-дән 15-кә кадәр;
- 16-дан 20-гә кадәр;
- 21-дән 25-кә кадәр;

6.2. «БикаФест» фестиваленең конкурс нигезендә сайлап алу этабына музыкаль һәм әдәби юнелешләренең конкурсантлары татар телендә төрле характердагы ике әсәр әзерлиләр. Конкурс нигезендә сайлап алу этабында катнашучы, үзе сайлап, аларның берсен казыйлар шурасына тәкъдим итә, кирәк булган очракта казыйлар шурасы икенче җырны башкаруны сорарга хокуклы.

6.3. Чыгыш ясау вакыты – дүрт минут. Чыгыш ясау вакыты регламенттан артса, фестивальнең казыйлар шурасы чыгыш ясауны бүлә ала.

6.4. Чыгыш ясау өчен музыка, фонограмма кирәк булган очракта ул электрон җайланмаларда ике экземплярда булырга тиеш. Электрон җайланманы оештыручыларга 22 ноябрь көнне теркәлү вакытында тапшырырга кирәк. Конкурсны оештыручыларның аккомпаниатор бирмәүләренә игътибар итүегезне сорыйбыз.

6.5. Электрон җайланмада катнашучының фамилиясе, исеме, шәһәре (районы), сайланган номинация, башкарылачак композициянең исеме күрсәтелгән булырга тиеш.

6.6. «Плюс» фонограммасына чыгыш ясаучылар конкурста катнаша алмый.

## 7. Акчалата кертем

Акчалата кертемнең бәясе һәр катнашучыдан 1800 (бер мең сигез йөз) сум тәшкил итә.

## 8. Нәтиҗәләр ясау

8.1. Һәр номинациядә, яшь һәм төркем категорияләрендә I, II, III урыннар билгеләнә. Фестивальдә җиңүчеләргә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

8.2.Конкурс нәтиҗәләре нигезендә һәр юнәлештә «Гран-при» иясе билгеләнәчәк.

8.3. Фестивальнең оештыру комитеты белән килешеп, Казыйлар шурасы махсус бүләкләр бирү хокукына ия.

8.4. Гомуми карар белән Казыйлар шурасы Фестивальдә Гран-при иясен билгеләмәскә хокуклы.

## 9. Оештыручыларның контактлары

Бәйгене оештыру комитеты Сәләт йортында (Казан, Островский ур., 23-нче йорт) урнашкан. Элемтәләр өчен телефон: 8 (843) 292-16-00. Эш сәгатьләре: 9:00-18:00. Сайт: www.selet.biz, ВК социаль челтәрендә: vk.com/selet.official.

## 10. Фестивальдә катнашучыларның шәхси белешмәләрен эшкәртү һәм яклау

Оештыручыларга бирелә торган мәгълүмат шәхси мәгълүматларга карый һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә саклана.

Республикакүләм фестивальдә катнашып, катнашучы Россия Федерациясенең 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон нигезендә катнашучының фестивальдә катнашуын тәэмин итү, оештыру турында мәгълүмат җиткерү һәм шундый ук чараларда катнашу максатында үзенең шәхси мәгълүматларын автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган эшкәртүгә ризалыгын бирә, шул исәптән: фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, телефон номеры, электрон почта адресы, эшләү/уку урыны, ил, төбәк, шәһәр. Фестивальдә җиңү яулаган очракта, күрсәтелгән шәхси мәгълүматлар бары тик оештыручылар тарафыннан гына кулланылачак һәм әлеге фестивальгә бәйле рәвештә бернинди өченче затларга да бирелмәячәк.

Фестивальдә катнашучыларның шәхси мәгълүматларын эшкәрткәндә оештыручылар Россия Федерациясенең 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон белән җитәкчелек итә. Оештыручылар шәхси мәгълүматны саклау өчен кирәкле, җитәрлек дәрәҗә терле оештыру һәм техник чаралар күрә.

Тиешле язма документны оештыручы адресына хат юллау ысулы яисә оештыручыларга шәхсән тапшыру юлы белән шәхси мәгълүматларны эшкәртү процессы туктатылырга мөмкин.